Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«18» ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, толлар һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм аларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунтлы вак таш түшәү.

Халык җыены рәисе: В.И. Гаврилов

Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов